РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

___04.12.2017__ № 1517

Саба муниципаль районы үзәге – Байлар Сабасы ш.т.п. нан
11 км дан да ерактарак урнашкан һәм
аз халыклы авыл җирлекләренә
көндәлек кирәк-ярак әйберләрне китерү буенча
кулланучылар җәмгыяте оешмалары
чыгымнарының бер өлешен каплау өчен
Саба муниципаль районы бюджетыннан
субсидия бирү тәртибен раслау турында

Саба муниципаль районы составына керүче җирлекләрнең ерактагы торак пунктларында яшәүчеләрне көндәлек кирәк-ярак әйберләр белән тәэмин итү максатларында, “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ нче Федераль законның 15 статьясы нигезендә һәм Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасы район үзәкләреннән 11 км дан да ерактарак урнашкан авыл җирлекләренә көндәлек кирәк-ярак әйберләрне китерүче оешмаларның транспорт чыгымнарын каплау өчен, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында”гы 2017 елның 20 ноябрендәге 887 нче карары нигезендә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Саба муниципаль районы үзәге – Байлар Сабасы ш.т.п. нан 11 км дан да ерактарак урнашкан һәм аз халыклы авыл җирлекләренә көндәлек кирәк-ярак әйберләрне китерү буенча кулланучылар җәмгыяте оешмалары чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Саба муниципаль районы бюджетыннан субсидия бирү тәртибе.

2. Саба муниципаль районы Финанс-бюджет палатасына(алга таба – ФБП) әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән субсидияләрне бирү максатларында, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының https://saby.tatarstan.ru рәсми сайтында субсидия бирү турында белдерү урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче Р.М. Гасимов

Татарстан Республикасы
Саба муниципаль районы
Башкарма комитетының
________________________
карары белән
РАСЛАНГАН

**Саба муниципаль районы үзәге – Байлар Сабасы ш.т.п. нан 11 км дан да ерактарак урнашкан һәм аз халыклы авыл җирлекләренә көндәлек кирәк-ярак әйберләрне китерү буенча кулланучылар җәмгыяте оешмалары чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Саба муниципаль районы бюджетыннан субсидия бирү тәртибе.**

**1. Субсидияләр бирү турында Гомуми нигезләмәләр**

**1.1.** Саба муниципаль районы үзәге – Байлар Сабасы ш.т.п. нан 11 км дан да ерактарак урнашкан һәм аз халыклы авыл җирлекләренә көндәлек кирәк-ярак әйберләрне китерү буенча кулланучылар җәмгыяте оешмалары чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Саба муниципаль районы бюджетыннан субсидия бирүнең әлеге тәртибе, Саба муниципаль районы үзәге – Байлар Сабасы ш.т.п. нан 11 км дан да ерактарак урнашкан һәм аз халыклы авыл җирлекләренә көндәлек кирәк-ярак әйберләрне китерү буенча кулланучылар җәмгыяте оешмалары чыгымнарының бер өлешен каплау өчен җирле бюджет акчалары исәбеннән субсидияләр бирү процедурасын билгели.

**1.2.** Кулланучылар җәмгыяте оешмаларына субсидияләр бирүнең максаты булып – Саба муниципаль районы үзәге – Байлар Сабасы ш.т.п. нан 11 км дан да ерактарак урнашкан һәм аз халыклы авыл җирлекләренә көндәлек кирәк-ярак әйберләрне китерү буенча кулланучылар җәмгыяте оешмалары чыгымнарының бер өлешен каплау тора.

**1.3.** Саба муниципаль районы үзәге – Байлар Сабасы ш.т.п. нан 11 км дан да ерактарак урнашкан һәм аз халыклы авыл җирлекләренә көндәлек кирәк-ярак әйберләрне китерү буенча кулланучылар җәмгыяте оешмалары чыгымнарының бер өлешен каплау өчен юнәлдерелә торган җирле бюджет акчаларының баш идарәчесе булып – Саба муниципаль районының Башкарма комитеты тора.

**1.4.** Субсидия бирү, әлеге тәртипнең 1.2. пунктында күрсәтелгән максатларга ирешү өчен, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының 2017 нче елга һәм 2018-2019 нчы елларның планлы чорына бюджеты турында” гы 2016 нчы елның 16 нчы декабрендәге 80 нче карарында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә гамәлгә ашырыла.

**1.5**. Субсидия бирү турында белдерү, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының http://saby.tatarstan.ru рәсми сайтында, субсидия бирү турында гаризалар кабул итү тәмамлануга унбиш көн кала урнаштырыла.

**1.6.** Субсидия алучылар булып, Саба муниципаль районы территориясендә теркәлгән һәм эшчәнлек алып баручы кулланучылар җәмгыяте оешмалары тора.

**1.7.** Субсидия алу хокукына түбәндәге критерийларга җавап бирүче оешмалар ия:

- Саба муниципаль районы территориясендә теркәлгән юридик зат;
- Саба муниципаль районы территориясендә субсидия алучының сәүдә эшчәнлеген гамәлгә ашыруы;
- Азык-төлек продуктларын ташу өчен транспорт чаралары булу;
- Саба муниципаль районының ерактагы торак пунктларына атнасына 1-4 тапкыр товарлар китерүне тәэмин итү;
- Үзгәртеп кору,бетү һәм банкротлык стадиясендә булмау.

**1.8.** Саба муниципаль район үзәге – Байлар Сабасы ш.т.п. нан 11 км дан да ерактарак урнашкан һәм аз халыклы авыл җирлекләренә көндәлек кирәк-ярак әйберләрне китерүче оешмаларга, субсидия, ягулык-майлау материаллары сатып алу өчен тотылган чыгымнар күләмендә бирелә.

**1.9.** Субсидия күләме тотылган чыгымнар суммасыннан чыгып билгеләнә, ләкин ул Саба муниципаль районы бюджетында бу максатларга каралган акчалардан да артыграк булырга тиеш түгел.

**1.10**. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы башкарма комитеты, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Саба районы буенча Казначылык Департаментының территориаль бүлегендә ачылган шәхси счетыннан оешмаларның исәп-хисап счетларына субсидияләр күчерүне гамәлгә ашыра.

## 2. Субсидияләр бирү шартлары һәм тәртибе.

**2.1.** Субсидия алу өчен, оешмалар, Саба муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына түбәндәге документлар белән бергә гариза тапшыра:

- Юридик затның (шәхси эшкуарның) дәүләт теркәве турында таныклык күчермәсе;
- Уставның күчермәсе (юридик затлар өчен) һәм аның оригиналы, шулай ук (булган очракта) аңа кагылышлы барлык үзгәрешләр һәм өстәмәләр ;
- Килешүнең күчермәсе яки зат төзү турында вәкаләтле органның карары һәм аның оригиналы;
- Салым исәбенә куелу турында таныклык күчермәсе;
- Транспорт чараларының булуын раслаучы документлар (техник чара паспортының күчермәләре һ. б.);
- Көндәлек кирәк-ярак товарларны һәм ашамлыкларны китерү өчен кирәк булган ягулык-майлау материалларын сатып алу чыгымнарының исәп-хисабы (беренчел документация белән бергә).

**2.2.** ФБП әлеге тәртипнең 2.1 пунктында күрсәтелгән документларның дөреслеген тикшерүне гамәлгә ашыра һәм Саба муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең 2012 нче елның 17 нче августындагы 1245 – п номерлы карары белән расланган, Саба муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр алу өчен язылган гаризаларны карау,бәяләү һәм җиңүчеләрне билгеләү Комиссиясенә, субсидия бирү турындагы мәсьәләне карау өчен оешмаларның гаризаларын тапшыра.

**2.3.** ФБП дан документлар һәм материаллар килгәннән соң, Комиссия аларны карый һәм субсидия бирү мөмкинлеге турында карар чыгара яки, сәбәпләрен күрсәтеп, субсидия бирүдән баш тарта.

**2.4**. Бурычка алучыга субсидия бирүдән баш тарту өчен нигез булып түбәндәгеләр тора:

- Бурычка алучы биргән документларның әлеге тәртипнең 2.1,2.6. пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яки күрсәтелгән документларны тапшырмау (тулысынча тапшырмау);
- Субсидия алучы тарафыннан бирелгән мәгълүматның дөреслеккә туры килмәве.

**2.5.** Комиссиянең карары уңай булган очракта, Башкарма комитет, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2015 нче елның 22 нче июлендә кабул ителгән 1001-п номерлы карары белән расланган Административ регламентның 2 нче кушымтасы нигезендә субсидия бирү турында килешү төзи һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Саба районы буенча Казначылык Департаментының территориаль бүлегендә ачылган шәхси счетыннан оешмаларның исәп-хисап счетларына субсидияләр күчерүне гамәлгә ашыра.

Субсидия бирү турындагы килешү 1 елга гамәлдә булу срогы белән төзелә.

Субсидияләр Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2015 нче елның 22 нче июлендә кабул ителгән 1001-п номерлы карары белән расланган административ регламентта билгеләнгән срокларда, тик документларны карау нәтиҗәләренә нигезләнеп, Баш идарәче белән килешү төзегәннән соң ун эш көненнән дә соңга калмыйча күчерелә.

**2.6.** Субсидия бирү турында Карар кабул итү планлаштырыла торган айның беренче числосына субсидия алуга дәгъва итүчеләрнең:

- Үз хезмәткәрләренә хезмәт хакы түләү буенча бурычлары булырга тиеш түгел;
- Бюджет кредитлары буенча бурычлары булырга тиеш түгел;
- Теләсә кайсы дәрәҗәдәге бюджетларга һәм бюджеттан тыш дәүләт фондларына исәпләнгән салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча, бухгалтерлык хисабы мәгълүматлары нигезендә претендент активлары баланс бәясеннән егерме биш процентка артып киткән бурычлары булырга тиеш түгел;
- Субсидия алучы юридик затларның эшчәнлеге үзгәртеп кору,бетү,банкротлык процессында булырга тиеш түгел,ә субсидия алучы шәхси эшмәкәрләр үз эшчәнлекләрен бетерергә тиеш түгел.
- Финанс операцияләре уздырганда мәгълүмат ачуны һәм бирүне күздә тотмаган һәм Салым салуның ташламалы салым режимын биргән,Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан расланган дәүләт яисә территорияләрдә теркәлгән,устав (җыелма) капиталында чит ил юридик затларының катнашу өлеше булган Россия юридик затлары,шулай ук, чит ил юридик затлары булырга тиеш түгел.
- Саба муниципаль районы үзәге – Байлар Сабасы ш.т.п. нан 11 км дан даерактарак урнашкан һәм аз халыклы авыл җирлекләренә көндәлек кирәк-ярак әйберләрне китерү буенча кулланучылар җәмгыяте оешмалары чыгымнарының бер өлешен каплау өчен, хокукый акт, башка норматив хокукый актлар яисә муниципаль хокукый актлар нигезендә Россия Федерациясе бюджетының субсидияләр бирү планлаштырыла торган өлешеннән акча алырга тиеш түгел.

**3. Субсидияләр бирүнең тәртибе,максатлары,шартлары үтәлешен контрольдә тотуны тормышка ашыру һәм аларны бозган өчен җаваплылык турында таләпләр.**

**3.1.** Бюджет акчаларының максатчан кулланылышын Саба муниципаль районының Контроль-хисап палатасы контрольдә тота.

**3.2**. Саба муниципаль районының Контроль-хисап палатасы субсидияләр бирү тәртибе,максатлары һәм шартлары үтәлешен тикшерә.

**3.3.** Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Контроль-хисап палатасы, муниципаль финанс тикшерүенең вәкаләтле органы,һәм Баш идарәче үткәргән тикшерүләр барышында, субсидия алучы тарафыннан шартларны бозу очраклары ачыкланса, бирелгән субсидия кире кайтарылырга тиеш.

**3.4.** Бирелгән субсидияләр, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы бюджеты кеременә, Башкарма комитетның субсидияләр алу өчен дөрес булмаган белешмәләр һәм документлар тапшыру фактларын ачыклау буенча тиешле таләбен алу датасыннан соң 60 көн эчендә кире кайтарылырга тиеш.

**3.5.** Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы бюджеты керемenә акчаларны ирекле рәвештә кире кайтарудан баш тарткан очракта, алар Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә мәҗбүри рәвештә түләттерелергә тиеш.

**3.6.** Бирелә торган документларның дөреслеге, бюджет акчаларын максатчан һәм нәтиҗәле файдалану, коррупциягә каршы законнарны үтәү өчен җаваплылык субсидия алучыларга йөкләнә. Закон бозучыларга карата гамәлдәге законнарда каралган җаваплылык чаралары кулланыла**.**

Саба муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Р.М. Гасимов